Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында шушы мәгълүмат белән хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) территориаль планлаштыру турында Нигезләмә
2) Торак пунктларның чикләренең урнашу тасвирламасы
3) Функциональ зоналар картасы;
4) Файдалануның махсус шартлары булган зоналар картасы (проект)

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

Ачык тыңлаулар 01.12.2025 елдан 25.12.2025 елга кадәр үткәрелә һәм түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
-гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу;
-проект экспозициясен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә, Түбән Чыршылы, Югары Чыршылы, Мордва Ивановка авылларында үткәрелә.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чершылы авыл җирлеге генераль планы проекты экспозициясен, ачык тыңлауларда каралуга тиешле, авыл җирлеге администрациясе бинасында түбәндәге адрес буенча: РТ, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Чершылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт; шулай ук Югары Чыршылы авылы, Горная урамы, 27 йорт; Мордов Ивановка авылы, Советская урамы, 13 йорт адресы буенча 2025 елның 8 декабреннән 25 декабренә кадәр ачарга.

Проект экспозициясе белән танышу вакыты – 9.00 дән 11.00 гә кадәр һәм 14.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучыларга генераль план проектына кагылышлы үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен язма рәвештә, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге адрес буенча кертергә тәкъдим итәргә: ТР, Лениногорск муниципаль районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт яисә Ramziya.Ivanova@tatar.ru, яисә 2025 елның 19 декабрендә гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү

барышында проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу журналына язма рәвештә яисә телдән язып кую юлы белән.

Язма рәвештә тәкъдим ителгән искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә документларның күчермәләре дә кушып бирелергә тиеш: физик затлар өчен яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга куелган һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2014 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документның күчермәсе; юридик затлар өчен - ЕГРЮЛдан өземтә.

Экспозиция эше барышында «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына экспозициягә килүчеләргә консультация бирүне оештырырга.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын билгеләргә:

2025 елның 19 декабрендә 16.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт;

2025 елның 19 декабрендә 17.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Югары Чыршылы авылы, Горная урамы, 27 йорт;

2025 елның 19 декабрендә 18.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Мордва Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт

2025 елның 9 декабренә кадәр генераль план проектын рәсми сайтта түбәндәге адрес: https://leninogorsk.tatarstan.ru/ «Авыл җирлекләре» бүлегендә буенча урнаштырырга.

Әлеге хәбәрне Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырырга, шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк урамы, 56 йорт; Югары Чыршылы авылы, Горная урамы, 27 йорт; Мордва Ивановка авылы, Совет урамы, 13 йорт.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
башлыгы — Хәйруллина Н.Я.